# ГАЛӘМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
«ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ
БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

***гыйнвар*** **№5**

2018 елның беренче уку атнасы башланып китте. Аның белән бергә мәктәбебездә Сәламәтлек айлыгы да старт алды. Мәктәп янында шугалак эшләп килә. Анда дәрес вакытында һәм дәресләрдән соң да шуарга мөмкин. Әле беренче тапкыр гына тимеарякка басучылар да яхшы шуалар. Шулай ук физик культура дәресләрендә укучылар чаңгыда да шуалар. Мәктәпнең 100% баласы да чаңгылар белән тәэмин ителгән.










Гыйнвар айлары кешелеккә тагын ГРИПП авыруларын алып килде. Вирус кына түгел салкын тию белән авыручылар да җитәрлек. Ничек итеп алардан сакланырга соң? Әлбәттә, саклану төрләре дә җитәрлек. Саф һавада йөрергә, җиләк-җимешләр, яшелчәләр белән тукланырга кирәк. Боларны үтәсәгез һичшиксез сәламәт булырсыз. Сәламәт тәндә – сәламәт акыл!

**Боз өсте кагыйдәләре**

1)Тимераякны яхшылап сайла. Алып торуга караганда үзеңнекен булдыру яхшырак.
2)Һава торышына карап киен.
3)Бозга чыгар алдыннан күнегүләр ясап ал.
4)Гәүдәңне дөрес тот.
5)Шугалакта шуу кагыйдәләрен исеңнән чыгарма. Шугалакта сәгать теле уңаена каршы шуалар



**“Олимпка юл”**

8-10 гыйнварларда Казанда математикадан "Путь к Олимпу" республика олимпиадасы уткәрелде. Бу олимпиада да инде икенче ел рәттән 8 нче сыйныф укучысы Гыйлемханова Энҗе катнашты.



**Сез булдырасыз! Афәрин!**

21 нче гыйнвар көнне Күгәрчен мәктәбендә башлангыч сыйныфлар арасында үткәрелгән бадминтон ярышларында безнең мәктәп укучылары Зиятдинов Инсаф һәм Шарипова Зилә 2 нче һәм 3 нче урыннарны бүлештеләр. Афәрин, укучылар! Һәр өлкәдә уңышлар сезгә.





Газета 2017 нче елның сентябрь аеннан айга бер тапкыр чыгарыла